**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИГЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

**№151** **26.11.2018 ел**

**«Бигеш авыл җирлеге башлыгын ай саен акчалата бүләкләү турында» 2018 елның 17 сентябрендәге 141 номерлы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге Советы карары үз көчен югалткан дип тану турында**

"Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында" 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында" 2018 елның 17 октябрендәге 940 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына, Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге Советы

**карар итте:**

1. Бигеш авыл җирлеге Советының «Бигеш авыл җирлеге башлыгының айлык премиясе турында» 2018 елның 17 сентябрендәге 141 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
2. Карар 2018 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **И.Р.Вәлиев**